



# Рөстәм ЯХИН: үзем турында

***Композитор Рөстәм Яхинның татар сәнгатендә кем икәнлеге, нинди дәрәҗәдә торганлыгы һәркайсыбызга яхшы мәгълүм.***

***Танылган җырчыбыз Илһам Шакиров аның хакында менә ничек гади һәм бик төгәл әйтә: "Безнең данлыклы композиторларыбыздан Рөстәм Яхин иҗатын бик хөрмәт итәм. Ул — чын профессионал, чын халыкчан композитор дип әйтер идем мин. Аның музыкасын бөтен җирдә уйныйлар".***

***Ул бит әле Татарстан дигән Ватаныбызның рәсми гимны авторы да. Ә инде аның иң популяр җырларыннан "Көзге романс", "Киек казлар", "Ялгыз агач", "Көзге моң", М.Җәлилнең "Моабит дәфтәре" шигырьләренә язылган вокаль триосы һаман да халык хәтереннән, сәхнәләрдән төшми.***

***Кеше үзе турында үзе язган икән — бу зур вакыйга. Безгә мондый мөмкинлекне музыка сәнгате белгече, профессор Мәхмүт Нигъмәтҗанов бүләк итте. Без аңа рәхмәт әйтәбез һәм Рөстәм Яхинның үз кулы белән язылган тәрҗемәи хәлен татар телендә бирәбез.***

Мин Казанның Пләтән тирәсендә, кондитер фабрикасы тоткан Ибраһим Апанаевлар йортында туганмын. Без анда янгыннан соң күчеп киткәнбез. Хуҗа безгә даими фатир табарга таләп куя. Сульяк Болак урамыннан фатир таптык та 1926 елга кадәр әнә шунда яшәп киттек. Минем беренче истәлекләрем әнә шушы йорт белән бәйләнгән.

Миннән бай кешенең сурәтен тасвирлап бирергә сораганнары хәтеремдә. Нәрсә инде: корсакны киердем, башны артка чөйдем дә артка таба егылдым. Бөтенесе рәхәтләнеп көлделәр. Бик матур бер кызга яшертен рәвештә шигырьләр язам. Иң мөһиме — шушы өйдә пианино бар. Кара клавишларга сугып-сугып, "моңнар" чыгарам, мине тыңлаучылар табыла.

1926 елдан соң без Калинин урамына күчтек. Әти аны арзан гына бәягә алды шикелле. Йорт яхшы, ике катлы, ләкин аны нишләптер "бәхетсез нигез" диделәр. Чөнки безгә кадәр бу өйдә бик еш авырганнар, бик еш үлгәннәр икән...

Аскы этажда да фатирчылар тора иде, алар да чирдән арынмыйлар иде. Җиләк-җимеш бакчасы бик бай иде. Сыер тәрбияләп карадык, ләкин озакка түгел. Мин печәнлектә йокларга бик ярата идем. Менә шунда кетәклектә язгы, беренче ап-ак йомыркаларны күргәч бик тә гаҗәпләнә торган идем.

Дусларым аз иде. Мин күп вакыт ялгыз йөрергә яраттым.

1929 елны мәктәпкә укырга кердем. Әтием белән килдек. Бөтен класс каршында укытучы сорай миннән: "Ялкау булмассыңмы?" Берни дә уйламыйча: "Булам!" дип җавап бирәм. Класста кычкырып көлделәр — әллә инде русчам шулайрак булган, әллә инде өр-яңа классташларым каршында югалып калдым микән?..

Шушы ук урамда, бездән ерак түгел, минем абыйның гаиләсе бай гына яшәп ята иде. Аларның Фәридә дигән кызлары музыка укытучысыннан шәхси дәресләр ала иде. Фәридә апа миңа сул кулдан ничек итеп аккордлар ясарга икәнне өйрәтте. Бу — гармония дөньясы белән минем беренче тапкыр танышуым иде. Ул мине укытучысына алып барды. Тик мин дәресләрне бик аз алдым. Фортепианода уйнау — егетләр эше түгел дип, әтием мине бу эштән тыйды.

Бервакыт безгә әтинең тугандаш сеңлесе Мәрьям Рахманкулова килде. Мин аның гаҗәеп моңлы тавышына гашыйк булдым. Татар халык көйләрен ул искиткеч оста башкара иде. Ул безнең өйгә кунакка килсә — вәт, минем өчен бәйрәм. Аның талантына һәм үзенең матурлыгына бик-бик күпләр мөкиббән иде шул!

Сөйләүләре буенча, мин, ике айлык вакытларымда ук инде, музыка ишетсәм, бик нык тәэсирләнәм, елыйм, тиз генә тынычлана алмыйм икән. Күрәсең, музыка дөньясының серле, илаһи һәм газаплы бер нәрсә булачагын, язмышыма үтеп керәчәген әнә шул чаклардан сиземләгәнмендер.

Әминә апам Кызыл Армия офицерына кияүгә чыкканнан соң безне кара бер тәкъдир эзәрлекләде. Кияү егетебезнең элегрәк йөргән бер кызы булган икән: ул, үч алу максаты белән, аларның яшь гаиләсенә төрлечә аяк чала башлады. Никах, бай гаиләгә "кызыгучы" кияү турында тиешле урыннарга шикаять яза бу кыз. Менә шуннан соң әтиебезнең кустарь хуҗалыгын, тауар әйләнешен үтә күпертеп, авыр салымнарга күмәләр. Юкса сезонлы тауарларда зур керемнәр булмый диярлек иде. Әлеге салымнар безнең гаиләне аяктан екты. Безнең бөтен байлыкны, мал-мөлкәтне тартып алдылар. Без бер нәрсәсез калдык. Ни акчабыз, ни алтын запасларыбыз юк. Әтинең тәҗрибәсе җитмәде булса кирәк, ул үзенең кустарь хуҗалыгын вакытсыз башлап җибәрде һәм моның өчен кыйммәт түләде.

Әтием — Мөхәммәтхаҗи Әбделфәттах углы — Мамадыш районында мулла гаиләсендә туган. Карендәш туганнары Мусиннарның "Азиатская обувь" дигән ширкәтендә эшли. Приказчик була, хуҗасының ышанычын яулагач, кассир дәрәҗәсенә күтәрелә.

1926 елда әти ялгызак-кустарь эше белән шөгыльләнә башлый. 1930 елда безне салым белән тар-мар итәләр, хәтта сөтне бик мул бирә торган аклы-каралы сыерыбызны тартып алалар. Менә шул чакта әткәй беренче тапкыр диярлек елап ала.

Аның музыкага аерым сәләте күренмәде. Бик тәртипле, үз-үзенә йомылучан кеше иде. Ләкин ул үзлегеннән русчага өйрәнде һәм Казан, Мәскәү газеталарын даими укып бара иде.

Әнием — Мәрьям Садыйк кызы Мусина 1886 елда азиат аяк киемнәре җитештерүче сәүдәгәрСитдыйк Мусин гаиләсендә туа. Өч хатыннан бабайның ба-



*Р.Яхин кулларында — моң дәрьясы.*

лалары күп булган. Беренче хатыны Хупҗамалдан — Рабига апа, Фатих абый, әнием Мәрьям. Башкаларыннан тагын биш бала.

Әбием үлгәннән соң әнием янында үги ана Бәдри кала. Балаларны ул бик еш рәнҗеткән, үзенә хөрмәт-мәхәббәт белән карауларын таләп иткән. Ситдыйк бабай моны теләмәгән, билгеле, әмма ул аны каты яраткан (чибәр хатын булган!) Әнием бик кискен холыклы булган һәм Бәдри апага "әни" дип дәшмәгән.

Бабам төс-кыяфәте белән шәрык кешеләренә тартым. Кара чәчле, коңгырт-кара күзләр — болар да аны Кавказ милләте вәкилләренә охшата. Кызулык та җитәрлек үзендә. Ул кызы Мәрьямнең минем булачак әтигә чыгуын теләгән. Ул чакта ата-ана теләге кыз бала өчен закун булган, билгеле. Бик яратып чыкмаса да, килешеп-аңлашып яшәгәннәр. Алты бала үстергәннәр, ләкин икесе яшьрәк чакта ук вафат була.

Әтиебез үлгәннән соң барлык йорт эшләре әни кулына кала. Ул бөтен гомерен безне — балаларын тәрбияләүгә бирде. Сәлим атлы туганым, эш эзләп, Урта Азиягә китте, чөнки аны, сәүдәгәр калдыгына чутлап, укырга алмыйлар иде. Казанга менә-менә кайтам дип йөргән чакларында 1932 елны тифтан үлде. Иң яраткан улларының берсен югалту әнкәмне тәмам хастага салды. 16 яше тулыр-тулмастан әллә кая чит җирләргә китеп гаип булсын әле балаң! Әнкәй мескен тын, салмак тавышы белән халык җырларын җырлап, үзенең тирән хәсрәтен тарата иде. Эш вакытында да әнә шулай җырлап йөрүен кайберәүләр аңларга теләмәгән: җырлап кына йөри, эше юк, янәсе...

Әнигә табигать тирән моң биргән, ул әле шигырьләр дә язган. Аның ихласи эмоциональлеккә, шигърилеккә корылган әлеге шигырьләр дәфтәрен хөрмәтләп саклый идек.

Әнигә булган иң зур рәхмәтем тагын шул: мал-мөлкәтне бүлешкәннән соң ул пианино сатып алды. Минем балачактагы эстетик карашларыма бу хәл, әлбәттә, зур йогынты ясады. Мин музыка дөньясына ныграк якынайдым. Әни үзе дә сыңар кул белән уйный иде. Сеңелем исә Сәйдәшев моңнарын уйнарга ярата. Өч яшемдә үк мин, кыска бармакларымны йодрыкка йомарлап, пианиноның кара клавишларыннан татар моңнарын "йолкып" чыгара башлаганмын. Сөйләүләренчә, дүрт яшемдә мин бик чибәр бер кызны күреп, аңа ике юллык шигырь белән эндәшкәнмен:

*Кашың кара, буең зифа,*
*Сине кемнәр сөймәсен?*

Тирә-яндагылар кычкырышып көлгәннәр, билгеле.

1930 елда мал-мөлкәтне һәм йортыбызны тартып алганнан соң без "хокуксызлар" рәтендә калдык. Туктаусыз фатир эзләү, күченеп йөрүләр башланды. Ярый әле күп кенә туганнарыбыз үзләренә сыендырды.

Музыкадагы җитди адымнарымның берсе — М.М.Рахманкуловалар өенә "радио өчен фортепианода уйнап карау өчен" кунакка чакырылу иде. Мәрьям Рахманкулова соңрак мине музыка мәктәбе директоры Р.Л.Поляковка алып килде. Ул зыялы, үз эшенә фанатикларча бирелгән якты бер шәхес булып истә калган. Музыканы аңлау сәләтемне тикшерде. Мине булачак укытучым А.В.Чернышева белән таныштырдылар. Ул да искиткеч яхшы педагог иде. Өенә дәресләргә йөрсәм, әбәд ашатмыйча җибәрмәс иде диярлек...

Җидееллыкны өч елда! — әнә шулай зур тырышлык, үҗәтлек белән эшләдем мин. Моцарт, Гайдн, Бах, Бетховен кебек классиклар иҗатына якынаю. Эчтән генә фортепиано концерты уйнарга хыялланып йөрим.

Р.Поляков, минем үтә тырышлыгымны күреп, безнең өйгә кечкенә генә инструмент-пианино куйдыруга иреште. Мәктәпне тәмамлаганнан соң, инде мин нык яратып өлгергән укытучыларым Мәскәүдә укуымны дәвам итү өчен зур тырышлык, ярдәм күрсәттеләр.

Мәскәүдәге кабатланмас музыка атмосферасы бөтен күңелемне, рухымны биләп алды. Консерваториянең Зур һәм Кече заллары илаһи матурлык, изгелек белән өретелгән иде. Менә дигән музыкантлар плеядасы, халыкара һәм бөтенсоюз конкурслар лауреатлары, аларның тантаналы-триумфаль концертлары... Ржев вокзалы тирәсендә яшәдем. Кыен чаклар иде, стипендия җитми — көненә бер котлет, булка кисәге.

Профессор Г.И.Литинский белән очрашу композиторлык язмышымны тамырдан үзгәртеп җибәрде. "Син кайдан?" — дип сорый. "Казаннан", — дим. "Татармы?" "Әйе", — дим. Литинский әйтә: "Ул чагында музыка яз. Скрипка өчен оркестрга пьеса яз. Тиздән Мәскәүдә булачак татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы өчен кирәк булачак ул". "Ничек инде, минем бит музыка язганым юк". "Барыбер яз, барып чыгачак синнән". Менә сиңа мә! Ирексездән яза башладым, Г.И. миңа шефлык итә. Шөгыльләнер өчен өенә дә барам. Казан ныклап декадага әзерләнә. Мәскәү декадасында минем пьеса яңгырарга тиеш иде.

Әмма 1941 елда Ватан сугышы башланып китте.

<u>Редакциядән.</u> Кызганыч, шушы урында язма өзелә. Датасы күрсәтелмәгән...

Русчадан Рашат НИЗАМИ тәрҗемәсе.

<u>Чыганак</u> : **Идел.- 2005.- № 6**